12. Назаров М.М. Массовая коммуникация в современном мире: методология анализа и практика исследований. – М., 2000.

13. Фатеева И. А. Медиаобразование: теоретические основы и опыт реализации. – Челябинск, 2007.

14. Феддров А.В. Медиаобразование и медиаграмотность. – М.: Директ-медиа, 2013. – 343 с.

15. Чичерина Н.В.. Концепция формирования медиаграмотности студентов языковых факультетов на основе иноязычных. Дисс… докт. пед. наук. – Санкт-Петербург, 2008. – 301 с.

***Л.Р. Насыйхова***
Казанский (Приволжский) федеральный университет
© Л.Р. Насыйхова

## ЛЕКСИКО-СТИЛИСТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ ФРОНТОВЫХ ДНЕВНИКОВ ХАЙРЕТДИНА МУЗАЯ

## ХӘЙРЕТДИН МӨҖӘЙ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕНЕҢ ЛЕКСИК-СТИЛИСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Аннотация.*** *Особое место в татарской публицистике периода Великой Отечественной войны занимают дневники, основными тематическими направлениями которых являются вера в победу, ненависть к фашизму, тема любви к Родине. Известный военный журналист Хайретдин Музай в своих дневниках описывает не только эпизоды войны, но подробно рассказывает о своих переживаниях, изображает красоту природы, выражает свое отношение к политической ситуации в мире. В текстах дневников функционирует военная лексика, зафиксирована лексика, характерная для армейской среды. Для усиления эмоциональности, придания тексту красочности автор активно использует все виды выразительных средств татарского языка (лексические повторы, гиперболы, метафоры, метонимии, окказионализмы, олицетворения, перифразы, сарказм, сравнения, синонимы, антонимы и др.). Для более точного эмоционального выражения ненависти к врагу в дневниках часто используется ирония.*

***Ключевые слова:*** *Хайретдин Музай, дневник, публицистика, татарский язык, стиль.*

***Abstract.*** *A special place in the Tatar journalism of the period of the Great Patriotic War is occupied by diaries, the main thematic areas of which are faith in victory, hatred of fascism, the theme of love for the Motherland. The famous military journalist Hayretdin Muzai in his diaries describes not only the episodes of the war, but tells in detail about his experiences, describes the beauty of nature, expresses his attitude to the political situation in the world. In the texts of the diaries, the military vocabulary functions, the vocabulary characteristic of the army environment is recorded. To enhance emotionality, to make the text colorful, the author actively uses all kinds of expressive means of the Tatar language (lexical repetitions, hyperbole, metaphors, metonymies, occasionalisms, personifications, periphrases, sarcasm, comparisons, synonyms, antonyms, etc.). For a more accurate emotional expression of hatred of the enemy, irony is often used in diaries.*

***Keywords:*** *Khairutdin Muzai, diary, journalism, Tatar language, style.*

Шагыйрь һәм прозаик Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов) 1901 елның 26 мартында хәзерге Башкортстан Республикасының Туймазы районы Төрекмән (1946 елдан Октябрьский шәһәре составына керә) авылында туа.

Унсигез яшендә Х.Мөҗәйне Кызыл Армиягә алалар, һәм шул вакыттан соң аның бөтен гомере хәрби хезмәткә бәйле рәвештә уза. Ул озак еллар чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшә. 1938 елда Хасан күле янында япон самурайларына каршы барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бер үк вакытта Х.Мөҗәй әдәби иҗат эше белән шөгыльләнергә дә вакыт таба: егерменче еллар ахырыннан башлап газета-журнал битләрендә аның хәрби торышка, чик сакчыларының көндәлек хезмәтенә багышланган һәм аларның уй-фикерләрен чагылдырган шигырьләре, очерклары һәм хикәяләре еш басыла. 1932 елны Казанда «Мылтыклылар» исеме белән шигырь, хикәя һәм очерклары тупланган аерым җыентыгы дөнья күрә.

Х.Мөҗәй Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, гвардияче полк командиры буларак, үзенә

йөкләнгән сугышчан бурычларны үтәүдә, гитлерчыларның сугыш башында өстенлек иткән гаскәри көчләренә каршы оборона һәм һөҗүм операцияләрен башкаруда күп тапкырлар кыюлык һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә. Ләкин 1942 елның җәендә, Харьков юнәлешендә һөҗүм хәрәкәтләре барышында Х.Мөҗәй командалык иткән полк дошман чолганышында кала һәм айдан артык сузылган авыр бәрелешләрдән соң, полктан исән калган авыр яралылар, шул җөмләдән полковник Х.Мөҗәй, фашистлар кулына әсир төшә.

Х.Мөҗәйне башка әсирләр белән бергә Германиягә озаталар. Ул әсирлектә дә фашизмга каршы көрәшен туктатмый: Мюнхен шәһәрендәге совет хәрби әсирләре лагеренда төзелгән интернациональ антифашистик яшерен оешма җитәкчеләреннән берсе буларак, әсирләр, Германиягә көчләп куып китерелгән совет гражданнары һәм немец эшчеләре арасында фашизмга каршы пропаганда җәелдерү, листовкалар, прокламацияләр төзү һәм тарату буенча актив эш алып бара. Яшерен оешма, пропаганда һәм соботажлар белән генә чикләнмичә, баш күтәрү өчен әсирләрне коралландыру чарасына да керешә. Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, озак газаплаулардан соң, үлем җәзасына хөкем итеп, 1944 елның 4 сентябрендә үлем карары гамәлгә ашырыла. Фашист палачлары ул көнне җәзалап үтергән туксан ике Дахау тоткыны арасында шагыйрь һәм язучы, совет офицеры – полковник Хәйретдин Мөҗәй дә була.

Х.Мөҗәйнең Ватан сугышы чоры әдәби мирасыннан «Сугыш көндәлеге» исемле язмалары сакланып кала. Бу язмалардан фронт балаларында автор кичергән сугыш күренешләре, совет солдаты һәм командирларының дошманга булган нәфрәте, фашизмны җиңүгә ышанычы документаль төгәллек, кырыс реализм белән сурәтләнә. Язмалар, татарча һәм рус теленә тәрҗемә ителеп, 1968, 1978 елларда аерым китаплар булып басылып чыга.

Х.Мөҗәйнең хәрби көндәлекләрне анализлау барышында аның тарафыннан сугыш вакыйгаларының гаять төгәл сурәтләнүен, шәхси кичерешләрнең тирән чагылуын күрдек. Көндәлекләрдә, хәрби очерклардагы кебек үк, хәрби, армия лексикасы күп кулланылган: маневр, окоп, оборона, атыш, штык, граната, пленный, өлкән сержант, ефрейтор, землянка, орудие,

цель, пулемет, автомат, снаряд, мина, батарея командирының ординарецы, пехота, атака, танк, артиллерия, орудие лафеты, шинель, эре калибрлы артиллерия, ут ача, коручы, һөҗүм, атака, бомбардировщик, шрапнельле снаряд, гильза һ.б.

Фашистларга карата эмоцияләрен төгәл чагылдыру өчен ул актив рәвештә ирония куллана: «Риббентроп белән Адольф бу нәрсәләр турында бик күп уйланган булсалар кирәк. Уйлана торгач, үзләренең дә җилкәләре кычытып киткәндер. Әгәр шулай икән, рус штыгы әзер ул аркаларны кашырга. Автор кайбер сүзләрен куштырнакларга алып, бу аудиториягә сүзнең киресен, капма-каршы мәгънәсен эзләргә мөмкинлек бирә. «Кире чигүләре өчен олы «аталары» ачуланды булса кирәк».

Төгәл фактологик мәгълүматлар – публицистиканың төп билгеләреннән санала. Мөҗәй әсәрләрендә урын атамаларына еш мөрәҗәгать ителә:

Прохоровка белән рәттән торган авылда (Мордовка) калган разведкадан «Немецлар һөҗүм башлады, сугышабыз» дигән хәбәр 8 сәгать ярымда алынды.

Автор текстка матурлык бирү, аны бизәү өчен төрле сурәтләү чараларын куллана. Алар текстны кызыклы һәм тәэсирле итә. Мәсәлән, синонимнар: сазлык – баткаклык, дус – иптәш, пакъ – саф, арыган, талган, йорт – өй, алып йөрәкле – гайрәтле, масаеп – тәкәбберләнеп, ачыклыйсы – төшенәсе һ.б.

Тел сурәтләү чараларыннан көндәлекләрдә антонимнар да актив эшкә җигелә: туган – үлгән, менә – төшә, тау итәге – тау түбәсе, ап-ак тау кап-кара була, салкын – эссе, килүен яхшы киләләр, ләкин ничек китәрләр, салкынча кул – кайнар маңгай һ.б.

Шулай ук метафоралар да уңышлы урын алган: пуля яңгыры, немецлар дулкыны, ут диңгезе, буш гильзалар тау булып өеләләр һ.б..

Дошман уты. Ут кына түгел, пуля яңгыры.

Җанландыру рәвешендәге чаралар кызыклы кулланыла: ялангач таулар, пулеметларның котырынып такылдаулары, үлем тырнагы һ.б.

Әсәрнең сәнгатьлелеге һәм сынландыру көче барыннан да элек, кешеләрнең хәрәкәтләрен, вакыйга урынын, сугыш күренешләрен күрсәтүдән гыйбарәт. Хәрби көндәлекләрдә динамик вакыйгалар турында хәбәр ителү сәбәпле, бирелә

фигыльләр аерым роль уйный, бигрәк тә үткән һәм хәзерге заман формалары: 9 минутлык артиллерия утыннан соң урамнарда өйләрдән өйләргә күчеп йөрүләр бетте. Окопларга керделәр.

Көндәлекләрдә чагыштырулар геройларның кәефләрен һәм кичерешләрен күрсәтеп бирү, шулай ук предметларга һәм күренешләргә автор бәясен тапшыру өчен хезмәт итә: оясындагы әрлән кебек, таракан кебек, төкерек кебек, саранча кебек, алтын сымак, төбе киселгән нарат кебек, карлыгач оясы кебек, дот штурмлаган кебек, җылы яңгыр яуган шикелле, койрыклы йолдыз кебек, җир ташсыман каткан, йөзен әйтерсең кара болыт каплаган, кан төсле, муены өзелгән юха елан кебек, саранчалар кебек, ятим бала кебек, пулялар кигәвеннәр кебек бызлап тора һ.б..

Без анализлаган көндәлекләрдә сугыш вакыйгаларының эмоциональ сурәте өчен хезмәт итүче фразеологизмнар да теркәлгән: дошманның бугазыннан тоту, пыр туздырып ташладылар, немец солдатының башына җитте, дошманны көрәп ташларга, йөрәге януына чыдый алмый, юлларын кисте, кешеләрне өзеп алып тураклап бетерү, дошман күкрәгенә кадак кага, җанын бирде, көлен күккә күтәрделәр, кызу канлы, измәсен изгәнбез, табан ялтыраталар һ.б..

Хәрби чор көндәлекләрендә рус теленнән алынмалар бик еш очрый: налет, наводка, судимостен алыштырдым, сугышчан охрана, проводник,пленныйлар, стройдан чыгара, сугышчан охранение, круговая оборона, наводчик, стереотруба, осколок, авиабомба, рота, котелок, осколоклар, ствол, немецлар, круговая оборона төзеп, ут көчләрен тиешенчә файдалана беләләр һ.б.

Гарәп-фарсы алынмалары да очраштыргалый: тәбәссем, әхваль-рухияләре, очрашу шәрәфенә һ.б.

Хәзерге татар әдәби теленә хас булмаган конструкцияләрне дә очратырга була: 8 сәгать ярым – 8 сәгать 30 мин яки тугызынчы ярты, чигә – чигенә, чигүчеләр – чигенүчеләр, карачкыл, кулъяулыгы, башларга кыя алмый, 20 ләп иптәшләр, кай урыннар һ.б.

Экспрессивлык бирү өчен көндәлек автор кабатлауларга да мөрәҗәгать итә: Барыбер гомер үтә инде, әйдә аның мәгънәсез, газаплы өлеше тизрәк, тизрәк үтә бирсен.

Журналистикада кулланыла торган иң кызыклы сөйләм чараларының берсе булган аллюзия Мөҗәй көндәлекләрендә еш

кулланыла: Авылларны бетерү – Кутузовтан калган нәрсә. Аңа тарихта бер генә кеше дә ачуланмый. Ул, Ватан файдасы өчен булгач, авыллар белән исәпләшеп тормаган.

Көндәлекләр авторларның шәхси кичерешләренә нигезләнгән булганга күрә, сүз гел беренче зат исеменнән алып барыла.

Хәрби көндәлекләрдә еш кына һава шартлары турында да сөйләнелә. Еш вакыйга булган урынның пейзажы тасвирлана. Бу очракта укучылар солдатларның табигый яшәү шартлары белән яхшырак таныша ала. Х.Мөҗәйнең көндәлек язмаларыннан кырыс Россия кышының дошманга карата рәхимсез булуын да күрәбез: Пленга алынган бер солдатны китерделәр. Өстенә карасаң, көлке дә, кызганыч та. Өстендә май ае киеме, бөтенләй туңган төсле күренә. Башындагы каскасы бәсләнеп, карлары бөтәрләнеп-бөтәрләнеп туңган.

Хәрби көндәлекләр тарихи вакыйгаларның характерын аңларга, сугыш хәлләрен дөрес итеп кабул итәргә мөмкинлек тудыра. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын чагылдырган хәрби көндәлекләрнең феномены милли публицистиканы объектив реконструкцияләү өчен мөһим шарт булып тора.

Өйрәнелгән көндәлекләрдә Ватан темасы, төрле милләт вәкилләренең дуслыгы, җиңүгә ышаныч, фашизмга карата нәфрәт төп тематик юнәлешләр булып тора.

**Әдәбият:**

Хәйретдин М. Сугыш язмалары: көндәлекләр, очерклар, хикәяләр, шигырьләр. – 2 басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 303 б.